МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.01.2021 Казан шәһәре №26

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибен һәм социаль предприятие статусына ия кече һәм урта эшкуарлык субъектлары исемлеген формалаштыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 29 ноябрендәге 773 номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 31 октябрендәге 2853-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 28 ноябрендәге 3079-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану мәсьәләләрен карауның бердәм тәртибен билгеләү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары – Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры Р.Р. Сибгатуллинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
26.01.2021 № 26 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: социаль якланмаган (зәгыйфь) гражданнарны эш белән тәэмин итүче яки мондый гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сата торган, шулай ук мондый гражданнар өчен билгеләнгән товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары (алга таба – КУЭ субъектлары) (алга таба – мөрәҗәгать итүче):

1.2.1. Гражданнарның түбәндәге категорияләрен эш белән тәэмин итә торган КУЭ субъектлары, алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча мондый категорияләрнең теләсә кайсысына (бер яки берничә шундый категориягә) караган затларның уртача исемлек саны КУЭ субъекты хезмәткәрләре арасында кимендә илле процент (мондый категорияләргә караган кимендә ике зат) булуы, ә мондый категорияләрнең теләсә кайсысына (бер яки берничә шундый категориягә) караган затларның хезмәте өчен түләү чыгымнарының хезмәт хакы түләү чыгымнарында кимендә егерме биш процент өлешен алып торуы шарты белән:

а) инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар;

б) балигъ булмаган балалар, шул исәптән инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм (яки) күпбалалы ата-аналар;

в) пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында);

г) балалар йортларыннан чыгарылган егерме өч яшькә кадәр затлар;

д) иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм хөкеме алынмаган яки үтәлеп бетмәгән затлар;

е) качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр;

ж) аз керемле гражданнар;

з) билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар;

и) әлеге пунктның «а»-»з» пунктчаларында күрсәтелмәгән, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар.

1.2.2. Әлеге Регламентның 1.2.1 пунктында күрсәтелгән категорияләр исәбендәге гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сата торган күрсәтүләр) КУЭ субъектлары (әлеге Регламентның 1.2.1 пунктында күрсәтелгән КУЭ субъектларыннан тыш). Шул ук вакытта алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча мондый эшчәнлекне гамәлгә ашырудан алынган керемнәрнең бер өлеше КУЭ субъектының гомуми кереме күләмендә кимендә илле процентын тәшкил итәргә тиеш, ә алдагы календарь елы өчен КУЭ субъекты тарафыннан алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста керем өлеше әлеге табыш күләменең кимендә илле процентын тәшкил итәргә тиеш (алдагы календарь елына чиста табышы булган очракта);

1.2.3. Әлеге Регламентның 1.2.1 пунктында күрсәтелгән категорияләр исәбендәге гражданнар өчен билгеләнгән товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган КУЭ субъектлары, аларның яшәешендәге чикләүләрен җиңәргә яки компенсацияләргә мөмкинлек бирә торган шартлар, шулай ук башка гражданнар белән тигез дәрәҗәдә җәмгыять тормышында катнашу мөмкинлекләрен тудыру максатларында, узган календарь елы нәтиҗәләре буенча мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алынган керемнәрнең бер өлеше КУЭ субъекты керемнәренең гомуми күләмендә кимендә илле процентын, ә КУЭ субъекты тарафыннан узган календарь елында алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста кеременең бер өлеше әлеге керемнең кимендә илле процентын тәшкил итү шарты белән (узган календарь елында чиста табыш булу очрагында), социаль предприятиеләрнең түбәндәге эшчәнлек юнәлешләре нигезендә:

а) көнкүрештә яшәеш эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеге;

б) сәламәтлек саклау чараларын үткәрүдә ярдәм күрсәтү, сәламәтлек торышындагы тайпылышларны ачыклау өчен системалы күзәтү юлы белән сәламәтлекне карап тотуга һәм саклауга юнәлдерелгән социаль-медицина хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеге;

в) социаль мохиткә яраклаштыру өчен психологик халәтне коррекцияләүдә ярдәм күрсәтүне күздә тоткан социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

г) үз-үзеңне тотуда тайпылышларны профилактикалауга юнәлдерелгән социаль-педагогик хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

д) эшкә урнашуга һәм хезмәткә яраклаштыруга бәйле башка проблемаларны хәл итүдә ярдәм итүгә юнәлдерелгән социаль-хезмәт хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеге;

е) коммуникатив потенциалны арттыруны,тернәкләндерүне һәм социаль яраклаштыруны, социаль тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтүне күздә тоткан хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

ж) медицина техникасын, протез-ортопедик эшләнмәләрне, программа белән тәэмин итүне, шулай ук инвалидлыкны профилактикалау яки инвалидларны тернәкләндерү (абилитацияләү) өчен генә кулланыла ала торган техник чараларны җитештерү һәм (яки) сату;

з) инвалидлар һәм пенсионерлар ялын һәм һәм аларны савыктыруны оештыру эшчәнлеге;

и) өстәмә белем бирү өлкәсендә хезмәт күрсәтү эшчәнлеге;

к) инвалидларның социаль, инженерлык, транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм транспорт, элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалана алуы өчен шартлар тудыру эшчәнлеге.

1.2.4. Иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә һәм җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә ярдәм итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы КУЭ субъектлары, алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан керемнәр өлеше КУЭ субъекты керемнәренең гомуми күләмендә кимендә илле процентын тәшкил итү, ә узган календарь елында КУЭ субъекты тарафынан мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста табыш өлеше әлеге табышның кимендә илле процентын тәшкил итү шарты белән (алдагы календарь елы өчен чиста табыш булган очракта), эшчәнлекнең түбәндәге төрләре исәбеннән:

а) гаиләне ныгытуга, балаларны гаилә тәрбиясе белән тәэмин итүгә, аналарга һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән психологик-педагогик һәм башка хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

б) балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру эшчәнлеге;

в) мәктәпкәчә белем һәм гомуми белем, балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә хезмәт күрсәтү эшчәнлеге;

г) төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүдә, үсештә һәм социаль яраклашуда кыенлыклар кичерүче укучыларга психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтү эшчәнлеге;

д) социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар хезмәткәрләрен һәм ихтыяри затларны (волонтерларны) укыту буенча мондый оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән эшчәнлек;

е) мәдәни-агарту эшчәнлеге (шул исәптән шәхси музейлар, театрлар, китапханәләр, архивлар, мәктәп-студияләр, иҗади остаханәләр, ботаника һәм зоология бакчалары, мәдәният йортлары, халык иҗаты йортлары эшчәнлеге);

ж) милләтара хезмәттәшлекне үстерүгә, Россия Федерациясе халыкларының үзенчәлеген, мәдәниятен, телләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуга һәм яклауга юнәлдерелгән хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

мәгариф, фән һәм мәдәният белән бәйле, аларны гамәлгә ашырганда ун процентлы ставка белән өстәмә кыйммәткә салым салынучы, мәгариф, фән һәм мәдәният белән бәйле вакытлы басма матбугат һәм китап продукциясенең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән вакытлы басма матбугат һәм китап продукциясе чыгару.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының гаризалары белән эшләү өчен җаваплы булып «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең Социаль өлкә инновацияләре үзәге тора.

1.3.1. «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең урнашкан урыны: Казан шәһәре, Петербург урамы, 28.

«Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең эш графигы: шимбә һәм якшәмбе, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар дүшәмбе-пәнҗешәмбе көннәрендә 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга көнне 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Җәмәгать транспорты белән килү:

1, 2, 31, 37, 47, 74 номерлы автобуслар белән «Артем Айдинов урамы» тукталышына кадәр;

метрода «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең белешмә телефоны: +7 (843) 222-90-60.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең рәсми сайты адресы : http://fpprt.ru/.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;
2) «Интернет» челтәре аша;

   «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең рәсми сайтында (http://fpprt.ru/);

   Министрлыкның рәсми сайтында (https://mert.tatarstan.ru/);

   Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә;

1.3.5. «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, рәсми сайты һәм электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендәге «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

мөрәҗәгать итүче – социаль предприятие статусын бирү максатында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән КУЭ субъекты;

социаль предприятие – социаль эшкуарлык өлкәсендә эшчәнлек алып баручы КУЭ субъекты;

социаль эшкуарлык – гражданнарның һәм җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешендә каралган шартлар нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлеге (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон);

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр округының яки муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә оештырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)). Гариза стандарт бланкта тутырыла.

Башка төшенчәләр һәм терминнар 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип тану | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибен һәм социаль предприятие статусына ия кече һәм урта эшкуарлык субъектлары исемлеген формалаштыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 29 ноябрендәге 773 номерлы боерыгы (алга таба – 773 номерлы боерык) белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 1 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 773 номерлы боерык белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану яки КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карар | 773 номерлы боерык белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 12 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Дәүләт хезмәте гариза теркәлгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көнлек чорда күрсәтелә.<br>Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) үткәрүне утырышын көтү вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына керми.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану яки КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карарны мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (почта буенча, электрон почта адресына) бирү (җибәрү) карар рәсмиләштерелгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | 773 номерлы боерык белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 12 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан ел саен агымдагы елның 1 маена кадәр тапшырыла. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге:<br>1) КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында мөрәҗәгать итүче – шәхси эшкуар, мөрәҗәгать итүче – юридик зат җитәкчесе яисә закон, башка хокукый акт яисә юридик затның гамәлгә кую документы нигезендә юридик зат исеменнән яисә ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкаләтле мөрәҗәгать итүче (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле заты) тарафыннан имзаланган гариза (алга таба – гариза).<br>Гаризаның киңәш ителә торган | 773 номерлы боерык белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 2-6 пунктлары;<br>209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | үрнәге әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән;<br>2) әлеге Регламентның 1.1-1.4 пунктларында күрсәтелгән документлар, 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән шартка (шартларга) карап, КУЭ субъекты  шуңа нигезләнеп, үзен социаль предприятие дип тануны сорап мөрәҗәгать иткәндә;<br>3) мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле затының гаризага һәм (яки) Тәртипнең 3-7 пунктларында күрсәтелгән документларга кул кую хокукын раслаучы ышаныч кәгазе (документлар ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил тарафыннан тапшырылган очракта);<br>КУЭ субъекты социаль эшкуарлык өлкәсендә үзе башкара торган эшчәнлекнең характеры һәм үзенчәлекләре турында киңәйтелгән белешмәләр бирү өчен әлеге пунктта каралган документларга өстәмә рәвештә, шулай ук социаль йогынты турында хисап та тапшырырга хокуклы. Социаль йогынты турында хисапның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге хисапның тапшырылмавы КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту өчен нигез була алмый.<br>1.1. 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган шартларга туры килгән КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1) гариза бирү датасына гамәлдә булган гариза бирүченең штат расписаниесе күчермәсе;<br>2) 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре арасыннан мөрәҗәгать итүче хезмәткәрләре белән хезмәт килешүләренең | |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәләре;<br>3) мөрәҗәгать итүче хезмәткәрләренең 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә кертелүен раслый торган документларның күчермәләре, – әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган, киңәш ителә торган исемлек нигезендә;<br>4) 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре арасыннан мөрәҗәгать итүче хезмәткәрләренең саны һәм хезмәт хакы турында белешмәләр. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән;<br>5) мөрәҗәгать итүченең Федераль законның 24[1] статьясының 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре исәбендәге хезмәткәрләренең персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыклары күчермәләре (персональ белешмәләрнең вәкаләтле органга КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану максатларында тапшырылганлыгына күрсәтеп).<br>1.2. 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган шартларга туры килә торган КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1) 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре исәбендәге гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сату турында белешмәләр. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән;<br>2) мөрәҗәгать итүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | тарафыннан № 209-ФЗ Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган керемнәрнең гомуми керемнәр күләмендәге өлеше турында һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан узган календарь елы өчен алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста керемнең әлеге керем күләмендәге өлеше турында белешмә (узган календарь елы өчен чиста табыш булган очракта). Әлеге белешмәнең киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән.<br>1.3. 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган шартларга туры килә торган КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1) 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек юнәлешләренә туры китереп, мондый гражданнар өчен аларның тормыш-көнкүрешендәге чикләүләрне җиңәргә яисә компенсацияләргә мөмкинлек бирүче шартлар тудыру, шулай ук җәмгыять тормышында башка гражданнар белән бертигез дәрәҗәдә катнашу мөмкинлеге тудыру максатларында, 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре өчен билгеләнгән товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында мәгълүматлар. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән;<br>2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан № 209-ФЗ Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 | |

| | | |
|---|---|---|
| | өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган керемнәрнең гомуми керемнәр күләмендәге өлеше турында һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан узган календарь елы өчен алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста керемнең әлеге керем күләмендәге өлеше турында белешмә (узган календарь елы өчен чиста табыш булган очракта). Әлеге белешмәнең киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән.<br>1.4. 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган шартларга туры килә торган КУЭ субъекты гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1) 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек төрләре арасыннан җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә ярдәм итүче иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында белешмәләр. Әлеге мәгълүматларны тапшыруның киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән;<br>2) мөрәҗәгать итүче тарафыннан № 209-ФЗ Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган керемнәрнең гомуми керемнәр күләмендәге өлеше турында һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан узган календарь елы өчен алынган, быелгы календарь елында мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) | |

| | | |
|---|---|---|
| | гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста керемнең әлеге керем күләмендәге өлеше турында белешмә (узган календарь елы өчен чиста табыш булган очракта). Әлеге белешмәнең киңәш ителә торган үрнәге әлеге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән.<br><br>Документлар формалары «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең рәсми сайтында (http://fpprt.ru/) «Социаль предприятиеләр исемлегенә керү» бүлегендә урнаштырылган.<br><br>Документларның төп нөсхәләре кәгазьдә түбәндәге ысулларның теләсә кайсы төре белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>1) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенә;<br>2) әлеге Регламентның 1.3.1 пунктында күрсәтелгән адрес буенча почта аша | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр тапшырыла:<br>Халыкны социаль яклау органнарыннан:<br>– Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе яисә күпбалалы гаилә статусын раслый торган башка документлар;<br>– балалар интернат-йортында булу турында белешмә күчермәсе;<br>– гражданинны аз керемле дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе;<br>– гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе. | 210-ФЗ номерлы Федераль закон; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы карар) |

| | | |
|---|---|---|
| алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе;<br>әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | Гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан:<br>– аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында документ күчермәсе;<br>– әти-әниненең берсенең үлеме турында таныклык күчермәсе;<br>– гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан туу турында таныклыкта баланың әтисе турындагы язуның ана сүзенә карап теркәлүе турында күрсәтелгән белешмә;<br>– баланың туу турында «Атасы» графасында сызыу куелган таныклык күчермәсе;<br>– баланың тууы (уллыкка алынуы, кызлыкка алынуы) турында таныклык күчермәләре.<br>Суд канцеляриясеннән:<br>– ата-ананың икенчесен билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе.<br>Опека һәм попечительлек органнарыннан:<br>– инвалид балага опека, попечительлек билгеләнүен раслый торган документларның (опека яки попечительлек башкарылуы турында килешү яки опека һәм попечительлек органыннан опекун яки попечитель билгеләнүе турындагы акт) күчермәләре.<br>Пенсия фондыннан яки Медик-социаль экспертиза бюросыннан:<br>– пенсия таныклыгы күчермәсе яки пенсия билгеләү турында Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы белешмәсе.<br>Пенсия фонды идарәсеннән:<br>– гражданинның Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яше (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче алдагы 5 ел двәамында) статусы алуын раслый торган документларның күчермәләре;<br>– инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе;<br>– физик затта физик һәм (яки) | |

| | | |
|---|---|---|
| | психологик үсештәге җитешсезлекләр билгеләнүен раслый торган документ күчермәсе (эш бирүче тарафыннан билгеләнә).<br>Хәрби комиссариаттан:<br>– хәрби билет күчермәсе.<br>Россия Эчке эшләр министрлыгы территориаль органының Полициянең участок вәкаләтлеләре бүлегеннән, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте территориаль органыннан:<br>– иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителү турында белешмә яки хөкем ителгәнлек һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булуы (булмавы) яки җинаять эзәрлекләвен туктату турында белешмә күчермәсе.<br>Россия Эчке эшләр министрлыгы территориаль органының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсеннән:<br>– качак таныклыгы яки мәҗбүри күченүче таныклыгы күчермәсе.<br>граждан торган Социаль ярдәм күрсәтү учреждениесеннән:<br>– социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар күчермәләре.<br>Әлеге пунктта күрсәтелгән документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый | |

| | | |
|---|---|---|
| | актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торганын да, документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны; | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартыла:<br>1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган, әлеге Регламентның 2.5 пунктында санап үтелгән документлар комплектлы булмаган (әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 1.1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш) һәм (яки) алардан булган белешмәләр дөреслеккә туры килмәгән очракта;<br>2) документларны тапшыру өчен Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән срок бозылган очракта | 773 номерлы боерык белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 10, 13 пунктлары |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе:<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны, шулай ук Тәртипнең 9 пунктындагы 5-7 абзацлар нигезендә «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең Социаль өлкә | 773 номерлы боерык белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | инновацияләре үзәгеннән алынган белешмәләрне һәм мәгълүматларны карау барышында мөрәҗәгать итүчене 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясының 1 һәм (яки) 2 өлешләрендә каралган социаль предприятие дип тану шартларына туры килмәве ачыкланган очракта, шул исәптән КУЭ субъектларының бердәм реестрында мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр булмаса;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | минуттан артык булырга тиеш түгел. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пунктындагы «д» пунктчасы |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү аны алган көнне гамәлгә ашырыла.<br>Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы, гаризага алынган номер беркетеп һәм аны алу датасын күрсәтеп, документ әйләнешенең билгеләнгән системасында теркәлә.<br>Гариза электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграция системасына тоташтырылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 880 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | җиһазландырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз үтеп керү өчен шартлар (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү);<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү,<br>сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 7 пункты нигезендә, махсус | |

| | | |
|---|---|---|
| | өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, сукырларны озатып йөри торган этне объектка кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>күрү сәләте буенча инвалидлар өчен Россия Икътисадый үсеш министрлыгының, ведомство буйсынуындагы органнар һәм оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларыннан файдалана алу шартлары;<br>инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;<br>кирәк булганда инвалид яшәгән урын буенча яки дистанцион режимда хезмәт күрсәтү мөмкинлеге;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналардан файдалана алу мөмкинлеге Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә тәэмин ителә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү урынына транспорт белән үтеп керә алу мөмкинлеге;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның, «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы, инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган | |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге яки файдалана алмау | вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша гамәлгә ашырылмый.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит Социаль өлкә инновацияләре үзәгенә 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин | 63-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен документлар кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) тапшырылган документларны белгеч тарафыннан тикшерү һәм КУЭ

субъектларын социаль предприятиеләр дип тану (яки КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип танудан баш тарту) турында бәяләмә һәм карар проекты формалаштыру;

5) Комиссиядә КУЭ субъектларының гаризасын һәм башка документларын карау һәм кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү;

6) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Социаль өлкә инновацияләре үзәгенә шәхсән, телефон һәм (яисә) почта буенча (шул исәптән электрон почта аша) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән рәсми мөрәҗәгатьнең формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча да. Кирәк булганда Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Электрон почта аша җавап мөрәҗәгать итүченең электрон почта адресына электрон документ формасында алынган мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң 15 көннән дә артмаган срокта җибәрелә.

Җавап әзерләү өчен тагын да күбрәк вакыт таләп ителгән очракта, индивидуаль тәртиптә телдән мәгълүмат җиткерә торган Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә кирәкле мәгълүматны алу өчен язмача рәвештә мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә яки телдән мәгълүмат җиткерү өчен аңа уңайлы булган башка вакытны билгели ала.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен документлар кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау өчен гаризаның һәм документлар комплектының Социаль өлкә инновацияләре үзәгенә тапшырылуы нигез булып тора.

Әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә формалаштырылган документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тарафыннан турыдан-туры Социаль өлкә инновацияләре үзәгенә тапшырыла яисә теркәлгәннәр исемлеге белән, кулга тапшыру турында белдереп, почта аша юллауның гомуми файдаланудагы почта элемтәсе операторлары аша җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле гариза белән документларны 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон документлар рәвешендә

электрон чаралардан һәм (яки) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып җибәрә ала.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.3.2. Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече:

гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итә;

гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки (электрон рәвештә);

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, белгеч мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче рәсми мөрәҗәгатьне һәм документларны почта аша (электрон почтадан) җибәргән очракта, Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша (электрон почтадан) җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече алынган гаризаны терки.

Ведомствоара гариза формалаштыру һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы аша документларны соратып алу таләп ителгән очракта, Социаль өлкә инновацияләре үзәге белгече бу хакта электрон формада Министрлык белгеченә хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Министрлык белгече, кирәк булган очракта, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Халыкны социаль яклау органнарыннан:

Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе яисә күпбалалы гаилә статусын раслый торган башка документлар;

балалар интернат-йортында булу турында белешмә күчермәсе;

гражданинны аз керемле дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе;

гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе.

Гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан:

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында документ күчермәсе;

әти-әниненең берсенең үлеме турында таныклык күчермәсе;

гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан туу турында таныклыкта баланың әтисе турындагы язуның ана сүзенә карап теркәлүе турында күрсәтелгән белешмә;

баланың туу турында «Атасы» графасында сызыу куелган таныклык күчермәсе;

баланың тууы (уллыкка алынуы, кызлыкка алынуы) турында таныклык күчермәләре.

Суд канцеляриясеннән:

ата-ананың икенчесен билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе.

Опека һәм попечительлек органнарыннан:

инвалид балага опека, попечительлек билгеләнүен раслый торган документларның (опека яки попечительлек башкарылуы турында килешү яки опека һәм попечительлек органыннан опекун яки попечитель билгеләнүе турындагы акт) күчермәләре.

Пенсия фондыннан яки Медик-социаль экспертиза бюросыннан:

пенсия таныклыгы күчермәсе яки пенсия билгеләү турында Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы белешмәсе.

Пенсия фонды идарәсеннән:

гражданинның Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яше (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче алдагы 5 ел дәвамында) статусы алуын раслый торган документларның күчермәләре;

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе;

физик затта физик һәм (яки) психологик үсештәге җитешсезлекләр билгеләнүен раслый торган документ күчермәсе (эш бирүче тарафыннан билгеләнә).

Хәрби комиссариаттан:

хәрби билет күчермәсе.

Россия Эчке эшләр министрлыгы территориаль органының Полициянең участок вәкаләтлеләре бүлегеннән, Җәзаларны үтәү федераль хезмәте территориаль органыннан:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителү турында белешмә яки хөкем ителгәнлек һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булуы (булмавы) яки җинаять эзәрлекләвен туктату турында белешмә күчермәсе.

Россия Эчке эшләр министрлыгы территориаль органының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсеннән:

качак таныклыгы яки мәҗбүри күченүче таныклыгы күчермәсе.

граждан торган Социаль ярдәм күрсәтү учреждениесеннән:

социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар

күчермәләре.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек итү органы белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгать документны һәм мәгълүматны бирә торган органга яки оешмага килгән көннән башлап 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәте хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатькә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап нәтиҗәсе булган мәгълүматлар (документлар) яки соралган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Тапшырылган документларны белгеч тарафыннан тикшерү һәм КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип тану (яки КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип танудан баш тарту) турында бәяләмә һәм карар проекты формалаштыру.

3.5.1. Социаль өлкә инновацияләре үзәге хезмәткәре мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны карый.

Документларны карау барышында Социаль өлкә инновацияләре үзәгенең җаваплы хезмәткәре:

документларны тапшыру сроклары турындагы шартлар үтәлешен тикшерә;

209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән шартлар үтәлешен тикшерү максатында, «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштырылган дәүләт хакимияте вәкаләтле органнары электрон сервисларыннан түбәндәге белешмәләрне ала:

– мөрәҗәгать итүчегә карата Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан/Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте сайты – https://egrul.nalog.ru/index.html);

– Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте сайты – https://ofd.nalog.ru).

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

документларда математик хаталар булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документлардагы белешмәләрне 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән шартлар белән чагыштыра;

социаль йогынты турында тапшырылган хисаптагы мәгълүматның

мөрәҗәгать итүчене социаль предприятие дип тану шартларына туры килүен тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынганнан соң 4 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларны тикшерү.

3.5.2. Социаль өлкә инновацияләре үзәгенең җаваплы хезмәткәре документларны карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчене социаль предприятие дип тану яки мөрәҗәгать итүчене социаль предприятие дип танудан баш тарту турында әлеге Регламентка 9 нчы кушымта нигезендә карар проекты әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене социаль предприятие дип тану турында (мөрәҗәгать итүчене социаль предприятие дип танудан баш тарту турында) карар проекты.

3.6. Комиссиядә КУЭ субъектларының гаризасын һәм башка документларын карау һәм кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү.

3.6.1. Социаль өлкә инновацияләре үзәге хезмәткәре Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаментының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү институтларын үстерү бүлеге (алга таба – Бүлек) җитәкчесенә комиссия утырышын уздыру өчен кирәкле КУЭ субъектларының гаризаларын карау йомгаклары буенча материаллар комплектын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә, ләкин утырышны үткәрү датасына кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән документлар комплекты.

3.6.2. Бүлек җитәкчесе документлар комплектын карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тапшырылган материалларны һәм карар проектын аңа тапшыра.

Бүлек белгече Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук комиссия тарафыннан карау өчен материаллар комплектларын формалаштыра.

Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган документлар Комиссия каравына әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында күрсәтелгән сроктан соң 30 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Комиссиянең составы һәм аның турындагы нигезләмә Министрлык боерыгы белән раслана.

Комиссияне Рәис җитәкли, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары.

Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер

тапкыр үткәрелә. Карау өчен сораулар булмаган очракта, Комиссия утырышы үткәрелми.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә документлар комплектын тапшыру, Комиссиядә карау өчен материаллар формалаштыру.

3.6.3. Комиссия секретаре:

комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра һәм аны Комиссия рәисенә раслау өчентапшыра;

Комиссия рәисе кушуы буенча Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын үткәрү турында хәбәр итә.

Комиссия утырышының көн тәртибе, шулай ук Комиссия утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында Комиссиядә Социаль өлкә инновацияләре үзәгеннән катнаша Комиссия секретаре Комиссия әгъзаларына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар утырыш үткәрү датасына кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыру һәм аны Комиссия әгъзаларына юллау.

3.6.4. Комиссия секретаре Комиссиядә карап тикшерүгә тәкъдим ителгән материаллар буенча чыгыш ясый һәм КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану (яисә танудан баш тарту) турында карар проектын игълан итә.

КУЭ субъектларын социаль предприятиеләр дип тану мәсьәләләрен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Министрлыкка КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану турында карар проектын раслауны тәкъдим итәргә;

Министрлыкка КУЭ субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карар проектын раслауны тәкъдим итәргә.

Комиссия утырышта катнашучылар арасыннан күпчелек тавыш белән карарлар кабул итә. Тавышлар тигез булган очракта, Рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

Процедураның нәтиҗәсе: мәсьәләләрне карау һәм карар кабул итү.

3.6.5. Комиссия секретаре тавышларны саный һәм алынган нәтиҗәне игълан итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсенә кертелә.

Комиссия карарлары Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул – Комиссия рәисе тарафыннан, ә ул булмаса – Комиссия рәисе урынбасары тарафыннан расланa.

Комиссия секретаре Комиссия утырышы беркетмәсен Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.6.4-3.6.5 пунктларында билгеләнә торган процедуралар утырыш үткәрелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тавышларны санау һәм беркетмә рәсмиләштерү.

3.6.6. Бүлек белгече, беркетмә нигезендә, КУЭ субъектларын социаль

предприятиеләр дип тану яисә танудан баш тарту турында Министрлык карарын рәсмиләштерә. Министрлыкның кабул ителгән карары формасы әлеге Регламентка 11 нче кушымтада билгеләнгән журналда теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән карар.

3.6.7. Бүлек белгече КУЭ субъектларын социаль предприятие дип тану (яисә танудан баш тарту) турында Министрлык карарын гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) бирә яисә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көндә (шәхси мөрәҗәгать иткәндә) яисә алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә (почта буенча карар җибәрелгән очракта) гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) карар.

3.6.8. Ел саен, агымдагы елның 5 июленнән соңга калмыйча, Министрлык Татарстан Республикасында социаль предприятие статусы булган КУЭ субъектлары исемлеген КУЭ субъектларының бердәм реестрын алып бару максатларында Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә тапшыра.

Юридик затның яисә шәхси эшкуарның социаль предприятие булып торуы турындагы мәгълүматлар ел саен, агымдагы календарь елының 10 августында әлеге Регламентның 3.6.6 пункты нигезендә Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә тапшырылган белешмәләр нигезендә КУЭ субъектларының бердәм реестрына кертелә.

Процедураның нәтиҗәсе: КУЭ субъектларының бердәм реестрында юридик затның яки шәхси эшкуарның социаль предприятие булып торуына күрсәтү.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы белдерүдә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны (алга таба – техник хата) төзәтү буенча административ процедураны башлау өчен техник хатаны төзәтү турында гариза алынуы нигез булып тора.

3.7.2. Техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хата булуын раслый торган документлар.

Техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки почта аша Министрлыкка тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.7.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза эшчәнлек бүлеге белгече тарафыннан теркәлә һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен

җаваплы белгечкә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгеч дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хата булуы турындагы гаризаны дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хата булу-булмавы предметына тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хата булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгеч документлардагы яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы белдерүдә булган техник хатаны бетерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хата булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгеч дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хатаның булмавы турында хәбәр әзерли.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләре үтәлешен агымдагы контрольдә тоту тәртибе.

Әлеге Регламентның үтәлешенә агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан җаваплы башкаручыларның әлеге Регламентны, Россия Федерациясе норматив хокукый актларын үтәвен һәм башкаруын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольдә тоту рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

- эш башкарылуына;
- документларны карау нәтиҗәләренең норматив хокукый актлардагы (әлеге Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
- документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;
- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру вакытлары һәм тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә эшчәнлекнең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең, «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе хезмәткәрләренең, «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе җитәкчесенә шикаять бирергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, норматив хокукый актларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең, «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфунк-

цияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mert.tatarstan.ru), «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясенең рәсми сайтыннан (http://fpprt.ru/); Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләре.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда, – теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә

шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит компаниясе, шулай ук аның вазыйфаи затлары яки хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Социаль предприятие дип тану турында
ГАРИЗА

_______________________________________________________________
(кече һәм урта эшкуарлык субъектының тулы исеме)

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына) юридик зат төзү (индивидуаль эшкуарны теркәү) турында язу кертү датасы – «__» _________ел, язу кертү фактын раслаучы документның сериясе һәм номеры, – _________________________________ ___________________________________________________, теркәүче орган атамасы – _____________ _______________________________________, ИНН________________________, КПП _____________, салым органында исәпкә кую датасы– «__»___________ ____ ел.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына мәгълүматлар кертү датасы– «__»___________ ____ ел.

____________________ исеменнән ышаныч кәгазеннән башка гына эш итәргә хокуклы зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче) турында белешмәләр: ___________________________________________________.

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), шәхесне таныклаучы документ исеме, номеры, аны бирү датасы, әлеге документны биргән органның исеме, вазыйфа атамасы)

Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД2) нигезендә, кодларын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре:

а)…;

б)…

… .

Мөрәҗәгать итүче турында мәгълүмат ___________________________________________________
«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: _____________________ ______________________________________________________________________ .
(кече һәм урта эшкуарлык субъектының (булган очракта) рәсми сайты)

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясына, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2019 елның 29 ноябрендәге 773 номерлы боерыгы белән расланган КУЭ субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенә таянып, ___________________________________________________________________________
(кече һәм урта эшкуарлык субъекты исеме)
социаль предприятие дип тануыгызны үтенәм.

Мөрәҗәгать итүче гаризада һәм аңа теркәп тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булуын гарантияли.

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2019 елның 29 ноябрендәге 773 номерлы боерыгы белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибендә каралган документлар кушымта итеп бирелә (____ биттә).

« _____ « _______________ 20 _____ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат
җитәкчесе)/Вәкаләтле зат

| | |
|---|---|
| ______________________ | ______________________________ |
| имза | (тулы имза) |

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Социаль йогынты турында хисап

| № | Бүлек | Тасвирлама |
|---|---|---|
| 1. | Социаль предприятиенең максаты | |
| 2. | Социаль предприятиенең эшчәнлеге аны хәл итүгә юнәлдерелгән социаль проблема (кулланучы ихтыяҗы) | |
| 3. | Социаль предприятие эшчәнлегенә юнәлдерелгән максатчан аудитория | |
| 4. | Социаль предприятие башкара торган социаль проблемаларны хәл итү ысуллары | |
| 5. | Социаль предприятие кулланучысына тәкъдим итеlә торган продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү) (максатчан аудитория) | |

« ____ « ______________ 20 _____ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат җитәкчесе)/Вәкаләтле зат

______________________ ______________________

имза (тулы имза)

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Гражданинны «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә кертүне раслый торган документлар исемлеге

| Гражданнар категориясе | Документлар (тиешле нигез булганда тапшырыла) |
|---|---|
| Инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар | инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмә күчермәсе;<br>физик затта физик һәм (яки) психологик үсештәге җитешсезлекләр билгеләнүен раслый торган документ күчермәсе (эш бирүче тарафыннан билгеләнә) |
| Балигъ булмаган балалар, шул исәптән инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм (яки) күпбалалы ата-аналар | баланың тууы (уллыкка алынуы, кызлыкка алынуы) турында таныклык күчермәләре;<br>инвалид балага опека, попечительлек билгеләнүен раслый торган документларның (опека яки попечительлек башкарылуы турында килешү яки опека һәм попечительлек органыннан опекун яки попечитель билгеләнүе турындагы акт) күчермәләре;<br>инвалидлык билгеләү («инвалид бала» категориясе билгеләнү) фактын раслаучы белешмә күчермәсе;<br>күпбалалы ата-аналар өчен:<br>Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе яисә күпбалалы гаилә статусын раслый торган башка документлар;<br>ялгыз ата-аналар өчен:<br>аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында документ күчермәсе;<br>ата-ананың берсенең үлүе турында таныклык күчермәсе;<br>гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан туу турында таныклыкта баланың әтисе турындагы язуның ана сүзенә карап теркәлүе турында күрсәтелгән белешмә;<br>ата-ананың икенчесен билгесез югалган дип тану яки вафат дип игълан итү турында суд карары күчермәсе;<br>яңа теркәлгән гаилә булмавын раслаучы документ күчермәсе (яңа гаилә теркәлүе турында тамга булмаган паспорт);<br>баланың туу турында «Атасы» графасында сызыу куелган таныклык күчермәсе |
| Балалар йортларыннан чыгарылган егерме өч яшькә кадәр затлар | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>балалар интернат-йортында булу турында белешмә күчермәсе |
| Пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында) | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>пенсия таныклыгы күчермәсе яки пенсия билгеләү турында Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы белешмәсе;<br>хәрби билет күчермәсе;<br>гражданинның Россия Федерациясе законнарында каралган пенсия алды яше (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче алдагы 5 ел двәамында) статусы |

| | |
|---|---|
| | алуын раслый торган документларның күчермәләре |
| Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм хөкеме алынмаган яки үтәлеп бетмәгән затлар | иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителү турында белешмә яки хөкем ителгәнлек һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булуы (булмавы) яки җинаять эзәрлекләвен туктату турында белешмә күчермәсе |
| Качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр | качак таныклыгы яки мәҗбүри күченүче таныклыгы күчермәсе |
| Аз керемле гражданнар | гражданинны аз керемле дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе |
| Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар | Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе; социаль ярдәм учреждениеләрендә булуны раслаучы документлар күчермәләре |
| Социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар | гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануны раслый торган, социаль яклау органыннан белешмә күчермәсе |

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Хезмәткәрләрнең саны һәм хезмәт хакы турында мәгълүмат

______________________________________________________________

(кече һәм урта эшкуарлык субъектының тулы исеме)

20 ___ елның «___» _____________ «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре арасыннан

| Т/с | Күрсәткеч атамасы | Алдагы календарь ел өчен хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны, кеше | Алдагы календарь ел өчен исәпләнгән хезмәт хакы фонды, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Барлык хезмәткәрләр | | |
| 2. | «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә караган хезмәткәрләр (2.1-2.10 юллар суммасы), шул исәптән: | | |
| 2.1 | инвалидлар | | |
| 2.2 | сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар | | |
| 2.3 | балигъ булмаган балалар, шул исәптән инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм (яки) күпбалалы ата-аналар | | |
| 2.4 | пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында) | | |
| 2.5 | Балалар йортларыннан чыгарылган егерме өч яшькә кадәр затлар | | |
| 2.6 | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | азат ителгән һәм хөкеме алынмаган яки үтәлеп бетмәгән затлар | | |
| 2.7 | Качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр | | |
| 2.8 | Аз керемле гражданнар | | |
| 2.9 | Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар | | |
| 2.10 | Социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар | | |

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә керүче хезмәткәрләрнең алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең уртача гомуми исемлегендәге саны (кеше), процентларда– ___________.

« _____ « _______________ 20 _____ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат җитәкчесе)/Вәкаләтле зат ____________________________ ________________________________

имза (тулы имза)

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сату турында белешмәләр

1. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләр исәбендәге гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сату турында гомуми мәгълүмат.

| Күрсәткеч атамасы | Җитештерелә торган товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) атамасы | Төзелгән килешүләр саны (килешү предметын күрсәтеп) | Алдагы календарь ел өчен сатудан кергән табыш (килешүләр буенча акча күләме), сум |
|---|---|---|---|
| Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә караган гражданнар, шул исәптән: | | | |
| инвалидлар | | | |
| сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар | | | |
| балигъ булмаган балалар, шул исәптән инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм (яки) күпбалалы ата-аналар | | | |
| пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында) | | | |
| Балалар йортларыннан чыгарылган егерме өч яшькә кадәр затлар | | | |
| Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм хөкеме алынмаган яки үтәлеп бетмәгән затлар | | | |
| Качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр | | | |
| Аз керемле гражданнар | | | |
| Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар | | | |
| Социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар | | | |

2. Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан җитештерелә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне) сату механизмын тасвирлау (ирекле рәвештә):

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

« _____ « _______________ 20 _____ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат
җитәкчесе)/Вәкаләтле зат

| | |
|---|---|
| ___________________________ | ___________________________ |
| имза | (тулы имза) |

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 2, 3 яки 4 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алдагы календарь елы нәтиҗәләре буенча алынган гомуми керемнәр күләмендәге керемнәр өлеше һәм узган календарь елы өчен алынган, агымдагы календарь елында мондый эшчәнлекне (мондый эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чиста табышның әлеге табыш күләмендәге өлеше турында белешмә

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 2, 3 яки 4 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алынган керемнәр турында һәм мондый эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга чыгымнар турында белешмәләр:

| Күрсәткеч атамасы | Күрсәткечнең әһәмияте: | | |
|---|---|---|---|
| | Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән эшчәнлектән | Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән эшчәнлектән | Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән эшчәнлектән |
| Узган календарь елында эшчәнлекне гамәлгә ашырудан алынган керемнәрнең гомуми күләме, сум | | | |
| Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 2, 3 яки 4 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алдагы календарь елында алынган керемнәр, сум | | | |
| Керемнәрнең гомуми күләмендә узган календарь елы нәтиҗәләре буенча Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 2, 3 яки 4 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашырудан алынган керемнәр өлеше, процент | | | |
| Алдагы календарь елында алынган чиста табыш күләме, сум | | | |
| Агымдагы календарь елында Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 2, 3 яки 4 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән табыш күләме, сум | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Алдагы календарь елында алынган чиста табышның агымдагы календарь елында Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 2, 3 яки 4 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлекне (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән табыш күләмендәге өлеше, процент | | | |

« _____ « ________________ 20 ______ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат
җитәкчесе)/Вәкаләтле зат ____________________ ______________________

имза (тулы имза)

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән граждан категорияләре өчен билгеләнгән, алар өчен аларның яшәешендәге чикләүләрне җиңү яки компенсацияләү мөмкинлеген бирә торган шартлар, шулай ук башка гражданнар белән бертигез дәрәҗәдә җәмгыять тормышында катнашу мөмкинлекләрен тудыру максатларында товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында
БЕЛЕШМӘЛӘР

1. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләр исәбендәге гражданнар өчен билгеләнгән, алар өчен аларның яшәешендәге чикләүләрне җиңү яки компенсацияләү мөмкинлеген бирә торган шартлар, шулай ук башка гражданнар белән бертигез дәрәҗәдә җәмгыять тормышында катнашу мөмкинлекләрен тудыру максатларында җитештерелә торган товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) турында гомуми мәгълүмат

| Максатчан аудитория | Җитештерелә торган продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү) төре | «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^1$ статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә продукциянең (товарларның, эшләрнең, хезмәтләр күрсәтүнең) җитештерелә торган төренең билгеләнеше | Алдагы календарь ел өчен продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү) сатудан кергән табыш, сум |
|---|---|---|---|
| Инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар | | | |
| балигъ булмаган балалар, шул исәптән инвалид балалар тәрбияләүче ялгыз һәм (яки) күпбалалы ата-аналар | | | |
| Пенсионерлар һәм пенсия алды яшендәге гражданнар (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында) | | | |
| Балалар йортларыннан чыгарылган егерме өч яшькә кадәр затлар | | | |
| Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм хөкеме алынмаган яки үтәлеп бетмәгән затлар | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр | | | |
| Аз керемле гражданнар | | | |
| Билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар | | | |
| Социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар | | | |

2. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категорияләр исәбендәге гражданнар өчен аларның яшәешендәге чикләүләрне җиңү яки компенсацияләү мөмкинлеген бирә торган шартлар, шулай ук башка гражданнар белән бертигез дәрәҗәдә җәмгыять тормышында катнашу мөмкинлекләрен тудыру өчен ярдәм итә торган товарларның (эшләрнең, хезмәтләр күрсәтүнең) үзлекләрен тасвирлау

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

« _____ « ________________ 20 _____ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат җитәкчесе)/Вәкаләтле зат ________________________ ________________________

имза (тулы имза)

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $24^{1}$ статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә ярдәм итүче иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә юнәлдерелгән һәм җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында

БЕЛЕШМӘЛӘР

| Эшчәнлек төре | Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД2) нигезендә эшчәнлек төрләре, кодларын күрсәтеп | Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү) сатудан алынган табыш, сум |
|---|---|---|
| гаиләне ныгытуга, балаларны гаилә тәрбиясе белән тәэмин итүгә, аналарга һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән психологик-педагогик һәм башка хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге | | |
| балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру эшчәнлеге | | |
| төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүдә, үсештә һәм социаль яраклашуда кыенлыклар кичерүче укучыларга психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтү эшчәнлеге | | |
| социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар хезмәткәрләрен һәм ихтыяри затларны (волонтерларны) укыту буенча мондый оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән эшчәнлек | | |
| мәдәни-агарту эшчәнлеге (шул исәптән шәхси музейлар, театрлар, китапханәләр, архивлар, мәктәп-студияләр, иҗади остаханәләр, ботаника һәм зоология бакчалары, мәдәният йортлары, халык иҗаты йортлары эшчәнлеге) | | |
| милләтара хезмәттәшлекне үстерүгә, Россия Федерациясе халыкларының үзенчәлеген, мәдәниятен, телләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калуга һәм яклауга юнәлдерелгән хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге | | |
| мәгариф, фән һәм мәдәният белән бәйле, аларны гамәлгә ашырганда ун процентлы ставка белән өстәмә кыйммәткә салым салынучы, мәгариф, фән һәм мәдәният белән бәйле вакытлы басма матбугат һәм китап продукциясенең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән вакытлы басма матбугат һәм китап | | |

| | | |
|---|---|---|
| продукциясе чыгару | | |

« _____ « ____________ 20 _____ ел.

Шәхси эшкуар (юридик зат җитәкчесе)/Вәкаләтле зат ____________________ ____________________

имза (тулы имза)

мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану (танудан баш тарту) турында
КАРАР
______________ № ______

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2019 елның 29 ноябрендәге 773 номерлы боерыгына 1 нче кушымта булып торучы Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 12 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мөрәҗәгать итүчегә карата карар кабул итте

______________________________________________________________________________
(*юридик затның исеме / шәхси эшкуар, ИНН, адрес (урнашу урыны)*)

социаль предприятие дип тану / танудан баш тарту турында.

Карар кабул итү нигезе:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану мәсьәләләре буенча комиссия тәкъдимнәре

(Комиссия утырышының ________ 202__ ел, № беркетмәсе),

Кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип тану тәртибенең 13 пунктындагы _ пунктчада каралган нигезләр булуы (*кече һәм урта эшкуарлык субъектын социаль предприятие дип танудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта күрсәтелә*).

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ________________ | ______________________ |
| (вазыйфа) | (имза) | (Фамилия, исем, ата исеме) |

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрына

__________________________________
(инициаллар, фамилия)

кемнән ______________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:___________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:___________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегез һәм тишле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм:
(кайда) __________________________________________ «___» ______________20__ ел. № ___________;
(документ исеме)
Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

____________________ ______________ ________________________________________________
(дата) (имза) (фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль предприятиеләр дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектын социаль предприятие дип тану (танудан баш тарту) турында карарларны теркәү журналы

| Юридик затның, шәхси эшкуарның исеме | Салым түләүченең тәңгәллек номеры | Элемтә өчен мәгълүмат | Карар № | Карар датасы | Документлар керү датасы | Карар төре | Комиссия утырышы беркетмәсе (датасы, номеры) | Баш тарту нигезләре (куллану мөмкин булса) | «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24[1] статьясындагы 1 өлешендә каралганнар исәбендәге, аның нигезендә мөрәҗәгать итүче вәкаләтле органга аны социаль предприятие дип тану өчен мөрәҗәгать иткән шарт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Тат
эш
пре
хез
рег

20___ елның «___» _____________ Татарстан Республикасында социаль предприятие стат
кече һәм урта эшкуарлык субъектлары исемлеге

| № | Кече һәм урта эшкуарлык субъектының исеме | Салым түләүчене тәңгәллек номеры |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Та
эш
пре
хез
рег

## ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮДӘ ТОТ
## ОРГАННАР ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

1. «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерциясез микрокредит к

| Вазыйфа | Телефон | |
|---|---|---|
| Генераль директорның беренче урынбасары, «Минем бизнес» департаменты җитәкчесе | +7 (843) 222-90-60, өст. 101 | |
| Социаль өлкә инновацияләре үзәге җитәкчесе | +7 (843) 222-90-60, өст. 211, 212 | |

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары – Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры | +7 (843) 524-91-12 | |
| Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаментының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм институтларын үстерү бүлеге җитәкчесе | +7 (843) 524-90-94 | |